Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ЯНУРУСОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯСАРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫҢ ЯНУРЫС
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423370, Татарстан Республикасы, Сарман районы, Янурыс
авылы, Ленин ур., 43 а йорт, тел.4-10-19

ИНН 1636005486 КПП 163601001 Р/С 40204810500000570023 БИК 049205001
ОГРН 1061687002574

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.01.2016 ел № 3

Янурыс ав.

Референдум уздыруны инициациялəү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һəм референдумда катнашу хокукының төп гарантиялəре турында» 2002 елның 12 июнендəге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендə җирле үзидарə оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендəге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарə турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Янурыс авыл җирлегенең 11 ст. нигезендə Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге советы КАРАР ИТƏ:

1. Җирле референдум уздыруны түбəндəге сорау буенча инициациялəргə: 2015 елда Янурус авыл җирлеге территориясендə яшəү урыны буенча теркəлгəн I төркем инвалидлардан, көндезге бүлек студентларыннан башка балигъ булган һəр кешедəн, җирле əһəмияттəге мəсьəлəлəрне хəл итүгə алынган акчаларны түбəндəге эшлəрне башкару буенча хəл итүгə 200 сум күлəмендə үзара салым кертүгə ризамы:

- җирлекнең торак пунктлары чиклəрендə беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тəэмин итү;
- җирлек территориясендə физик культураны һəм массакүлəм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рəсми физкультура-савыктыру һəм спорт чараларын үткəрүне оештыру;

Җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру

җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнарның исемнәре һәм йортларның номерлары белән күрсәткечләр урнаштыруны, кече архитектура формаларын урнаштыруны да кертеп);

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту

- җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

- җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

- каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;

-җирлек чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

-җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына иркле керүен тәэмин итү дә керә.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Янурыс авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе А. А. Мөхәммәдиева